ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_09.06.2023_ Мөслим авылы № 287_

**«Мөслим муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 ноябрендәге 663 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турындагы карарына үзгәрешләр кертү хакында» гы карары нигезендә Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Мөслим муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 ноябрендәге 663 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр, Татарстан Республикасында формалашкан «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр Министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән гражданнар арасыннан бер ата-анасы (законлы вәкилләре) махсус хәрби операциядә катнашкан ата-аналардан (законлы вәкилләрдән), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләреннән балаларны (гаилә әгъзаларын) бушлай кайнар туклану белән тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Л.Я. Хәбибуллинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе И.Ф. Салихҗанов**